ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 10 статьяларына һәм “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның $6^2$ өлешендәге икенче җөмләсенә “билгеләнгән таләпләргә” сүзләреннән соң “, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә” сүзләрен өстәргә;

2) 10 статьяда:

а) 10 өлештә “Капиталь ремонт буенча региональ программага” сүзләрен “Капиталь ремонт буенча региональ программаны актуальләштергәндә аңа” сүзләренә алмаштырырга;

б) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төрләрен төгәлләштерү, капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзе билгеләгән тәртиптә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә

ашыруның кыска сроклы (еллык) планнарын расларга тиеш. Җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актында капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау каралган булса, шушы норматив хокукый актта билгеләнгән тәртиптә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын расларга тиеш.";

в) түбәндәге эчтәлекле 11[1] өлеш өстәргә:

"11[1]. Региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнары түбәндәге принциплардан чыгып төзелә:

1) Россия Федерациясе Торак кодексының 185 статьясында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, региональ оператор счетындагы, счетларындагы алдагы елда файдаланылмый калган акчаларны һәм агымдагы елда капиталь ремонт өчен кертемнәр керүнең фаразланган күләмен капиталь ремонт максатларына тоту;

2) региональ оператор счетында, счетларында капиталь ремонт өчен акча җыелуның факттагы дәрәҗәсеннән чыгып, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләр күләмен төзәтү кирәклеге.".

**2 статья**

"Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2015 елның 5 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 7 пунктының "д" пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш) төшереп калдырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2016 елның 3 октябре
№ 77-ТРЗ